Аксубай районы «Иске Кыязлы топ гомумбелем биру мэктэбе»нен мэктэпкэчэ торкеме

Кабул ителде:
Пед. Жыелыш
Протокол №
“1” 29.08. 2018ел

**Раслыйм:**
Иске Кыязлы топ гомумбе-
лем биру мэктэбе директоры
_________/Мугинов И.С./

“31” 08 2018ел
приказ № 52

**Укыту - эш программасы**
**2018-2019 нче уку елына мәктәпкәчә төп бердәм укыту программасын тормышка ашыру**
**кечкенәләр төркеме (3-4 яшьлекләр)**

Тәрбиячеләр Залальтдинова Р.А.
Шамсутдинова З.Г.

2018 ел.

**Аңлатма язуы**

«Туганнан алып мәктәпкә кадәр» (Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева) гомуми белем бирү программасы федераль дәүләт таләпләреннән чыгып төзелде.

Бөтен белем бирү өлкәннәрнең интеграциягә корылган якынча комплекслы-тематик планлаштыру 2 нче кечкенәләр төркемендә эшләүче тәрбиячеләр өчен методик ярдәмлек булып тора.Ул, «Туганнан алып мәктәпкәчә» белем биру программасына нигезләнеп язылган.(Н,Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева) <u>Программаның төп бурычлары</u>: мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыймматле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхси культурасының нигезлеге җирлеген формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләренә яраклаштырып физик, психик сыйфатларны төрле яклап үстерү.

Күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртү сәләтле үсеш дәвам итә, бу яшьтә иҗади күзаллау сәләте үсә башлый.

<u>Программаның максатына ирешү өчен таләпләр:</u>

- балаланың сәламәтлеген, эмоциональ иминлеген төрле яклап үстерү
- группада һәр балага гуманлы, ягымлы мөнәсәбәт булдыру
- балаларның барлык төр эшчәнлекләрен югары дәрәҗәдә кулану
- тәрбия һәм белем бирү процессына иҗади якын килү (креативлык)
- баланың иҗатын үстерүдә белем бирүнең төрле вариантларын куллану
- бала иҗатына хөрмәт белән карау
- бала тәрбияләүдә гаилә белән бергә эшләү

- балага басым ясамыйча; физик һәм акыл күнекмәләрен нормада тоту.

**1.2. Икенче кечкенәләр төркеменең үсеш үзенчәлекләре(3-4 яшь)**

3-4 яшьлек балаларга күбрәк ситуациягә бәйләнмәгән аралашу хас. Бу яшьтә балалар олыларны кабатларга тели. Балаларның бу теләге аларның мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Бу каршылыкны балалар уеннар аша чишәләр. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төп эше – уен. Бу чорда уенның дәвамлылыгы кыска, сюжетлары гади бер-ике рольдән тора. Кагыйдәләргә нигезләнгән уеннар, бу чорда, формалаша гына башлый әле.

- Сурәтләү эшчәнлеге балаларның предметларны күзаллауларына бәйле була. Рәсемнәрдә кайбер детальләр төшеп калырга мөмкин.
- Вак моторика үсешенә әвәләү зур йогынты ясый. Алар үрнәк буенча гади предметларны әвәли алалар.
- Кисеп ябыштыруның гади төрләрен башкара алалар.
- Конструкцияләүдә үрнәк буенча яки уйлап чыгарып катлаулы булмаган корылмалар төзи алалар.
- Хәтер күләме, игътибарлылык үсә. Балалар 3-4 сүз, 5-6 предметның исемен истә калдырырга сәләтле. Алар олылар кушкан эшне истә калдыра, кечкенә шигырьләрне ятлый алалар.
- Бу чорда уйлап чыгару, хыялый фикерләү сәләте үсә. Ул күбрәк уеннарда чагылыш таба. Балалар бер-берсе белән мөнәсәбәткә кермичә янәшә уйныйлар. Бу яшьтә конфликт уенчык бүлешү вакытында барлыкка килә.
- Җенес аермалылыгын аңлау, үз-үзеңә бәя бирү үсеш ала. Бу бигрәк тә уенчыклар сайлаганда күренә.

**1.3. Программаның төп максатлары:**

- Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләү.
- Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану.

- Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игътибар итү. Балаларны бар яклап та сәламәт шәхес итеп үстерү, аңа мәктәптә уку–тәрбия алу өчен кирәкле психологик процесслар булдыруны максат итеп куябыз.

Тәрбиячеләр тарафыннан балалар бакчасының укыту-тәрбия планнары, шөгыльләрнең расписаниесы һәм календарь планнары төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында шул расписание буенча тәрбиячеләр даими рәвештә балалар белән шөгыльләнәчәкләр.

### 1.4. Программаны тормышка ашыру принциплары, алымнары:

- Үстерелешле белем бирү принцибы (аның нигезендә баланың үсеше тора),
- Фәнгә нигезләнгән һәм практик кулланышлы булу принцибы,
- Интеграция принцибы (баланың яшь үзенчәлекләрен күз алдында тоту),
- Комплексно-тематик принцип (балаларның төрле эш төрләрен бер темага нигезләү)
- Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен күз алдында тоту принцибы,
- Балаларның һәм олыларның үзара килешеп эшләү принцибы,
- Гаиләләр белән берлектә үзара килешеп эшләү принцибы
- Гендорлы алым,
- Милли-төбәк компонентына нигезләнү принцибы.

**Икенче кечкенәләр төркеме өчен бердәм аралашу челтәре.**

***Дүшәмбе: 1. Иҗади сәгать. Рәсем.***
***2.Физкультура.***
***Сишәмбе:1. Танып белү. Әйләнә-тирә дөнья белән танышу.***
***2.Музыка.***
***Чәршәмбе:1 .Аралашу. Сөйләм телен үстерү, матур әдәбият белән таныштыру.***
***2.Физкультура.***
***Пәнҗешәмбе:1. Танып белү. Иң гади математик күзаллау булдыру.***
***2.Музыка.***
***Җомга:1. Иҗади сәнгать. Әвәләү. Кисеп ябыштыру.***

***2.Физкультура.***

### Иң гади математик күзаллау булдыру

***Сан.*** Бертөрле предметлар формалаштыру күнекмәләрен үстерү.

***Зурлык.*** Капма-карша размердагы предметларны чагыштыру (зур өй-кечкенә өй)

***Форма.*** Предметларны формалары буенча чагыштырырга һәм аларны атарга өйрәтү (кубик, кирпич, шар)

***Әйләнә-тирәдә ориенлаштыру***. Әйләнә-тирәдә ориенлаштырырга һәм аны практикада кулланырга өйрәтү. Үз гәүдәсенең өлешләрен дөрес әйтергә өйрәтү.

***Геометрик фигураларны аерырга*** (квадрат, түгәрәк, өчпочмак) ярдәм итү.

### Иң гади математик күзаллау булдыру буенча тематик план

| № | Бурычлар | Дата |
|---|---|---|
| 1. | Аерым предметлардан группа төзергә өйрәтү.Исемнәрне күплек, берлек санда әйтергә өйрәтә башлау | |
| 2. | Төркемнән бер предметны аерып алырга һәм аерым предметны төркемнәргә берләштерергә өйрәтү.Санны исем белән берлектә килештереп әйтергә өйрәтү. | |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Зурлыклары буенча төрле предметларны аерырга ярдәм итү. «Кечкенә», «Зур» сүзләрен кулланышка кертү. | |
| 4. | Карточкадагы предметлар саны шундый ук сандагы әйберләр белән чагыштырырга өйрәтү. «Бер», «Күп» төшенчәләрен аңлап кулланышка кертү. | |
| 5. | Аерым предметлардан төркем төзергә һәм шул төркемнән аерым предметларны аерып алырга өйрәтү.«Күп», «Бер», «Берәү дә юк» сүзләрен аңлап кулланышка кертү. | |
| 6. | «Бер-күп» төшенчәләрен аңлап куллануларына ирешү.Мөстәкыйль эш итәргә өйрәтү. | |
| 7. | Зурлыклары капма-каршы предметларны аерырга өйрәтү. «Зур», «Кечкенә» сүзләрен кулланышка кертү. | |
| 8. | Сан һәм предмет исемен дөрес итеп кулланырга өйрәтү. Тәрбияче күрсәтмәсе буенча эшләү күнекмәләре булдыру. | |
| 9. | Әзер обстановкада «бер» һәм «берничә» предмет табарга ярдәм итү.«Ничә?» соравына «бер», «күп» дип җавап бирүләренә ирешү. Янәшә һәм берсе өстенә икенчесен куеп предметларны чагыштырырга өйрәтү. | |
| 10. | Махсус обстановкада «бер» һәм «берничә» предмет табарга ярдәм итү. «Ничә?» соравына «бер», «күп» дип җавап бирүләренә ирешү.Янәшә һәм берсе өстенә икенчесен куеп предметларны чагыштырырга өйрәтү. | |
| 11. | «Күп» һәм «бер» генә предмет табарга булышу.Түгәрәк, квадратны аерырга, исемнәрен атарга өйрәтү. | |
| 12. | Махсус төркемнәр арасыннан бер һәм күп әйберләрне табарга өйрәтү. Квадрат, түгәрәкне танып аерырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 13. | Ике предметны озынлыклары буенча чагыштырып, «озын-кыска» «озынрак-кыскарак» сүзләрен кулланышка кертергә ярдәм итү. | |
| 14. | Әйләнә тирәлектә бер һәм күп предметлар табарга өйрәтү. Түгәрәк һәм квадратны танып аерырга өйрәтү.Предметларны озынлыклары буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 15. | Янәшә кую юлы белән ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтү.<br>« Күбрәк», «Тигез» сүзләрен кулланышка кертү.<br>Уң һәм сул кулларны аерырга өйрәтә башлау. | |
| 16. | Янәшә кую юлы белән предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәтү.<br>Чагыштыру нәтиҗәсен кулланышка кертү.<br>Ике төркем предметларны чагыштырып «тигез» «шулкадәр» сүзләре белән әйтергә өйрәтү. | |
| 17. | Янәшә һәм берсе өстенә икенчесен куеп предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәтү.<br>«Киң-тар», киңрәк-таррак» сүзләрен кулланышка кертү. | |
| 18. | Зурлыклары капма-каршы предметларны чагыштырырга өйрәтү.<br>Зур-кечкенә сүзләрен иркен кулланырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 19. | Ике тигез предметлар җыелмасын чагыштырып, «тигез», «никадәр», «шулкадәр» сүзләре белән аңлатырга ярдәм итү.<br>Өчпочмак белән таныштыру. Аны квадрат белән чагыштырырга өйрәтү. | |
| 20. | Таныш геометрик фигураларны (түгәрәк, квадрат, өчпочмак) аерырга өйрәтү.<br>«өстә-аста» төшенчәләрен аңларга булышу. | |

| | | |
|---|---|---|
| 21. | Предметларны озынлыклары буенча чагыштырып, «озын-кыска» «озынрак-кыскарак» сүзләрен кулланышка кертү.<br>Янәшә кую юлы белән ике төркем предметларны чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 22. | Ике предметны озынлыклары буенча чагыштырып, «озын-кыска» «озынрак-кыскарак» сүзләрен кулланырга өйрәтү. | |
| 23. | Ике тигезсез төркем предметларны чагыштырып « күп-аз», «никадәр-шулкадәр» сүзләрен кулланышка кертү.Озынлыклары төрле булган предметларны чагыштырырга өйрәтү. | |
| 24. | Озынлыклары төрле булган предметларны чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 25. | Озынлыклары төрле булган предметларны чагыштырырга өйрәтү күнекмәләрен үстерү.<br>«Өстә», «аста» төшенчәләрен үзләштерергә ярдәм итү. | |
| 26. | Ике төркем предметларны янәшә кую һәм берсе өстенә икенчесен куеп чагыштырырга һәм «никадәр-шулкадәр», «күбрәк-азрак» сүзләрен кулланырга өйрәтү. | |
| 27. | Ике предметны киңлекләре һәм озынлыклары буенча чагыштырып, туры килгән сүзләрне кулланырга өйрәтү.<br>Түгәрәк, квадрат, очпочмакны танып аерырга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 28. | Үрнәк буенча тавыш белән предметлар санын билгеләргә ярдәм итү.<br>Таныш геометрик фигураларны танып аеру күнекмәләрен үстерү. | |
| 29. | Үзеннән өстә, аста, алда, артта торган предметларны атарга ярдәм итү. | |
| 30. | Күп һәм бер хәрәкәтне, аларның санын, «бер», «күп» сүзләре белән атарга өйрәтү. | |
| 31. | Әйләнә-тирәдәге юнәлешне билгеләп, «алда-артта», «өстә-аста», «уңда-сулда» сүзләрен дөрес кулланырга ярдәм итү. | |
| 32. | Ике тигез һәм тигез булмаган предмет төркемнәрен чагыштырып, «күп-аз» сүзләрен иркен кулланышка кертү.<br>Өстә, аста сүзләрен кулланып пердметларның торышын билгеләргә ярдәм итү. | |
| 33. | Геометрик фигураларны дөрес итеп атарга өйрәтү: түгәрәк, квадрат, өчпочмак, шар, куб. | |
| 34. | Геометрик фигураларны дөрес итеп атарга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 35. | Янәшә һәм берсе өстенә икенчесен куеп предметларны киңлекләре буенча чагыштырырга өйрәтү.<br>«Киң-тар», киңрәк-таррак» сүзләрен кулланышка кертү.<br>Түгәрәк, квадратны танып атауларына ирешү. | |

**Аралашу белем бирү өлкәсе.**
**Сөйләм телен үстерү һәм матур әдәбият белән таныштыру.**

Балаларны матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру-сөйләм үсешенең әһәмиятле чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру процессында түбәндәге бурычлар чишелә:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итү.
2. Әдәби сөйләм үстерә.

3. Сөйләм сәнгатенә якынайту, шул исәптән эстетик зәвык, әдәби әсәрне аңга алуларны үстерү.

Икенче кече яшьтәге балалар эшчәнлеген оештыру комплеслы-тематик принципка нигезләнә.

Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә.

Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалыштыруга: физик яктан үчеш алган, төп культура-гигена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре аралашу ысулларын үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә.

План ел дәверендә «Сау бул җәй», «Көз», «Мин һәм минем гаиләм», «Минем йортым», «Яңа ел бәйрәме», «Кыш», «Ватанны саклаучылар көне», «Сигезенче март», «Яз», «Җәй» кебек темаларны үзләштерүне күздә тота.

**Матур әдәбият белән таныштыру һәм сөйләм телен үстерү буенча (аралашу) тематик план**

| | Тема | Бурычлар | Дата |
|---|---|---|---|
| 1 | Ә.Бикчәнтеваның “Туп-туп,тубыбыз”шигырен уку | 1.Балаларга шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү,аерымсүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2.Кабул итү сәләтен ,хәтернең уңай эмоцияләрен үстерү.<br>3.Уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. | |
| 2 | Л.Толстойның “Өч аю “әкиятен уку | 1.Күләмле булган әкиятләрне аңлауларына ирешү.<br>2.сангатьле сөйләм телен үстерү.<br>3.Әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү. | |
| 3 | Г.Бакирның”Сания инде зур үсте”хикәясен уку | 1.Балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау.<br>2.Ишетү игътибарын үстерү.<br>3.З,С авазларын дөрес әйтергә өйрәтү. | |
| 4 | Ә.Ерикәйнең “Көз” шигырен яттан сөйләү | 1.Әсәрнең эчтәлеген аңларга ,аны истә калдырырга булышу.<br>2.Көзге матурлыкка соклану хисләре тәрбияләү. | |
| 5 | А.Толстойның”Зирәк чәүкә”хикәясен уку | 1.Әсәргә карата кызыксыну уяту.<br>2.Балаларда уңай эмоциональ халәт булдыру.<br>3.хезмәткә уңай караш тәрбияләү.<br>4.Завазын дөрес әйтергә өйрәтү | |
| 6 | М.Мазуновның”Октябрь» шигырен яттан сөйләү | 1.Әсәрнең эчтәленген аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>2.Көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү.<br>3.Монологик сөйләмнәрен үстерү. | |
| 7 | М. Җәлилнең “Әтәч”шигырен уку.<br>Ә-А авазлары | 1.Әдәби әсәрне тыңлау һәм кабул итү күнекмәләре формалаштыру.<br>2.Йорт кошларын тышлары буенча танырга өйрәтү.<br>3.Аларга карата рәхимлелек тәрбияләү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | “Кәҗә бәтиләре һәм бүре”әкиятен сөйләү | 1.Сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтү.<br>2.Халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. | |
| 9 | А.Алишның “Куян кызы”әкиятен уку. | 1.Әкиятне аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>2.Сүз тыңларга өйрәтү.<br>3.Өлкәннәр белән аралашу теләге булдыру. | |
| 10 | Җ.Тәрҗемановның “Маэмай”шигырен уку.М авазы. | 1.Әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>2.Зур булмаган фразаларны истә калдырырга ярдәм итү.<br>3.Йорт хайваннары белән таныштыруны дәвам итү. | |
| 11 | “Төлке куян һәм әтәч”р.х.әкиятен сөйләү. | 1.Балаларны әкият белән таныштыру,эчтәлеген аңларга ярдәм итү.<br>2.Яңа сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру. | |
| 12 | Ә.Ерикәйнең”Беренче кар”шигырен уку. | 1.Әсәр аша табигать белән таныштыру.<br>2.Сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру.<br>3.Шатлык хисләре булдыру. | |
| 13 | М.Фәйзуллинаның “Чебиләр зарядкасы”шигырен уку | 1.Йорт кошлары белән таныштыруны дәвам итү.<br>2.Олылар белән аралашу теләге булдыру.<br>3.Сүз тыңлаучанлык сыйфатлары формалаштыру. | |
| 14 | Г.тукайның “Ак бабай”шигырен уку. | 1.Кышкы табигатькә соклану хисләре тәрбияләү.<br>2.Гайлә турында тулырак аңлату.<br>3.Бабайларга хөрмәтле булу. | |
| 15 | Ә.Бикчәнтәеваның”Салкын саф һава”шигырен уку | 1.Авыр әйтелешле кайбер сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү.<br>2.Кар һәм аның үзлекләре белән таныштыру.<br>3.Сәламәт яшәү вәвеше булдыру. | |
| 16 | Ә.Кариның “Чаңгы шуабыз”шигырен уку.Ч авазы. | 1.Саф һавада төрле сплрт уеннары белән таныштыру.<br>2.Әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>3.Ч авазы кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү. | |
| 17 | “Төлке белән Аленушка”р.х.әкиятен сөйләү | 1.Яңа әсәр белән таныштыру.<br>2.Тәрбиячене тыңларга өйрәтү.<br>3.Әкият геройлары белән кызыксындыру. | |
| 18 | “Теремкәй”р.х.әкиятен уйнау | 1.Балаларда артистлык сыйфатлары формалаштыру.<br>2.Тәрбияче белән аралашу теләге булдыру.<br>3.Уңай сыйфатлар табарга булышу. | |
| 19 | А.Алишның”Чукмар белән Тукмар”әкиятен уку | 1.Башлаган җөмләне тәмамларга өйрәтү.<br>2.Дуслык,татулык хисләре тәрбияләү.<br>3.Өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү. | |
| 20 | Ә.Кариның”Тавык”шигырен уку.К авазы | 1.Йорт кошлары белән таныштыруны дәвам итү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 2.Калын әйтелешле К авазын сүзләрдә куллану.<br>3.Әбиләр белән аралашу теләге булдыру. | |
| 21 | Р.Батулланың”Елак әтәч”әкиятен уку | 1.диалогик сөйләмнәрен үстерү.<br>2.Гигиена кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү.<br>3.Әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү. | |
| 22 | Р.Корбановның “Уяу саклый”шигырен уку | 1.Патриотик тәрбия бирү.<br>2.Янәшә тартыкларны дөрес итеп әйтергә өйрәтү.<br>3.Сүзлекләрен активлаштыру. | |
| 23 | Ш.Маннурның”Яратам”шигырен уку | 1.Эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>2.Әти-әниләргә,туганнарга мәхәббәт хисләре тәрбияләү.<br>3.Шигырьне истә калдырырга булышу. | |
| 24 | Кояш гомере телим мин,әнием сиңа! | 1.Әниләр бәйрәме турында белемнәрен киңәйтү.<br>2.Ә авазын ачык әйтүләренә ирешү.<br>3.Әниләргә мәхббәт ярату хисләре тәрбияләү. | |
| 25 | Г.Нәбиуллинаның “Әнигә булышам”шигырен уку | 1.Кайбер фразаларны кабатлап,сөйләмнәрен активлаштыру.<br>2.Сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү.<br>3.Хезмәт сөючәнлек хисләре тәрбияләү. | |
| 26 | Яз.Колын һәм бәрән турында сөйлибез. | 1.Тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя төзергә,капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне таба һәм куллана белергә өйрәтү.<br>2.Хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. | |
| 27 | Ш.Галиевның”Гөлләр сусап утыра”шигырен уку | 1.Бүлмә гөлләрен тәрбияләү турында алган белемнәрен арттыру.<br>2.Өлкәннәр белән бергә эшләү теләге булдыру.<br>3.Кабул итү сәләтләрен арттыру. | |
| 28 | Р.Батулланың”Нурбәк әкияте”н уку | 1.Уенчыкларда әкият геройларын танырга һәм атарга өйрәтү.<br>2.Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.<br>3.Күзәтүчәнлек тәрбияләү. | |
| 29 | “Йомры икмәк”р.х.әкиятен сәхнәләштерү | 1.Әкият геройлары ярдәмендә әкиятнең эчтәлеген ачарга ярдәм итү.<br>2.Шар әвәләү күнекмәсен ныгыту.<br>3.Әкиятләр белән кызыксыну булдыру. | |
| 30 | Автобуста сәяхәт | 1.Аваз ияртемнәрен әйтә белүләренә ирешү.<br>2.Иркәләп ,яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру.<br>3.Тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. | |
| 31 | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә”шигырен уку | 1.Шигьри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 2.*Кәҗә,чирәм,сакал* сүзләре хисабына сүзлек байлыгын арттыру.<br>3.Хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. | |
| 32 | Ж.Тәрҗемановның “Йокы бабай”әкиятен сөйләү | 1.Әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү.<br>2.Сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы булдыру.<br>3.Көндәлек режимның үтәлешен күзәтү. | |
| 33 | Г.Таһировның “Йокла курчак”шигырен уку | 1.*Ә,Ү* авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйәтү.<br>2.Кайгыртучанлык сыйфатлары булдыру.<br>3.Үзара аралашу теләге булдыру. | |
| 34 | “Чуар тавык”р.х.әкиятен уку | 1.Халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>2.*Чуар,алтын,күкәй,тычкан* сүзләре хисабына сүзлекләрен баету.<br>3.Әкият геройлары белән кызыксыну булдыру. | |
| 35 | “Тор-тор,тургай!”такмагын өйрәнү | 1.Фольклор әсәрләре белән кызыксындыруны дәвам итү.<br>2.Кошлар турында белемнәрен арттыру.<br>3.Такмакның эчтәлеген аңларга ярдәм итү. | |
| 36 | К.Д.ушинскийның “Казлар”хикәясен уку | 1.Казларны,үрдәкләрне аера белергә өйрәтү.<br>2.Күплек һәм берлек сандагы исемнәрне дөрес кулланырга өйрәтү.<br>3.Йорт кошлары белән кызыксыну тәрбияләү. | |

**Иҗади сәнгать.**

**Рәсем.**

Балаларга рәсемдә әйләнә-тирәдәге предметларның һәм табигатьнең матурлыгын сурәтләп бирергә тәгъдим итү. Карандаш, фломастер, пумаланы мускулларны киеренкеләндермичә һәм бармакларны каты кысмыйча, дөрес итеп тотарга өйрәтү. Пумаланы буяуга дөрес итеп манырга өйрәтү.

Төс исемнәрен белүләрен ныгыту (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара. Төсмерләр белән таныштыру (алсу, зәңгәрсу, соры.)

Декаратив эшчәнлеккә тарту. Дымково бизәкләре белән төрле- төрле предметларны бизәргә өйрәтү (кош, кәҗә, ат, савыт-саба, бияләй һ.б.)

Сызык, штрих, буялыш (мазки), тимгел-тимгел тапларны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү (агач яфраклары коела, яңгыр ява, кар ява)

Төрле юнәлештә туры сызыклар (озын, кыска) сызарга, аларны кисештерергә өйрәтү.

Бер үк предмет сурәтен кабатлау юлы белән катлаулы булмаган сюжетлы композицияләр иҗат итү күнекмәләре формалаштыру.

**Рәсем шөгыле буенча тематик план**

| | Тема | Бурычлар | Дата |
|---|---|---|---|
| 1 | Яңгыр ява | -әйләнә-тирәлек, табигать турында күзаулларны бирергә өйрәтү.<br>-рәсемдә яңгыр күренешен сурәтләргә өйрәтү.<br>-кыска сызыклар сызарга өйрәтү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Көзге keләм | -пумала белән эш итәргә өйрәтә башлау.<br>-төсләр белән таныштыруны дәвам итү<br>-көзге табигать турында белемнәрне киңәйтү. | |
| 3 | Көчле яңгыр | -тоташ штрихлар ясарга өйрәтү.<br>-әйләнә-тирәдән алган белемнәрне кулланышка кертү. | |
| 4 | Көзге яфраклар | -пумалаларны дөрес тотарга өйрәтү.<br>-буяуга манып яфраклар ясарга өйрәтү.<br>-образлы күзаллау булдыру. | |
| 5 | Җил исә | -карандашны кәгазьдән аермыйча кушылган түгәрәкләр ясарга өйрәтү.<br>-үз эшенең нәтиҗәсенә сөенергә өйрәтү. | |
| 6 | Ирекле темага | -рәсем темасын мөстәкыйль уйларга мөмкинлек бирү.<br>-уйлау, фантазияләү сәләтен үстерү | |
| 8 | Матур туплар | -түгәрәк формадагы предметларны ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>-үзеннең эшенә унай эмоцияләр булдырырга ярдәм итү. | |
| 9 | Төсле кыңгыраулар | -пумаланы кәгазьдән аермыйча тоташ боҗралар ясарга өйрәтү.<br>-төсләрне бутамыйча дөрес кулланырга өйрәтү. | |
| 10 | Тәлинкә | -түгәрәк формадагы предметларны ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>--пумалаларны дөрес тотып, буяулар белән дөрес эш итәргә өйрәтү. | |
| 11 | Ирекле тема | -рәсемнең эшчәнлеген мөстәкыйль уйлап табарга, уйлаганны тормышка ашырырга ярдәм итү.<br>-хезмәт нәтиҗәсенә сөенә белергә өйрәнү. | |
| 12 | Зур һәм кечкенә кар йомарламнары | -түгәрәк формадагы предметлар ясау күнекмәләрен үстерү<br>-рәсемне кәгазь битендә дөрес урнаштырырга өйрәтү. | |
| 13 | Агачлар | -рәсемдә агач образы тудырырга өйрәтү<br>-туры, вертикаль, авыш сызыклар ясарга өйрәтү | |
| 14 | Чыршыкай | -туры, вертикаль, авыш сызыклардан торган предметлар ясарга өйрәтү. | |
| 15 | Яңа ел чыршысы | -бизәлгән чыршы образы тудырырга ярдәм итү<br>-чыршыны зур итеп ясарга өйрәтү<br>-чыршыны бизәгәндә төрле төсләр куллануларына ирешү | |
| 16 | Бияләй өйне бизибез | -әкиятле образ тудырырга булышу<br>-фантазияләү, иҗади эш мөмкинлеген бирү | |
| 17 | Уйлау буенча ясау | -өйрәнгән алымнарны кулланып рәсем ясау алымнарын үстерү<br>-темага туры китереп ясауларына ирешү | |
| 19 | Уйлау буенча ясау | -рәсем ясау күнекмәләрен үстерү<br>-мөстәкыйльлек тәрбияләү | |
| 20 | Кар бабай | -күңелле кар бабай рәсемнәре ясау теләге булдыру<br>-түгәрәк формадагы предметларны ясарга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 21 | Кояш елмая | -кояш образы тудырырга ярдәм итү<br>-рәсемне тема буенча тулыландырырга өйрәтү | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22 | Самолет | -берничә өлештән торган предметлар ясарга өйрәтү<br>-рәсемдә предмет образын бирергә өйрәтү | |
| 23 | Кышкы агачлар | -кышкы агачларны ясарга өйрәтү<br>-берничә агач ясау теләге булдыру | |
| 24 | Курчакларга кирәкләр | -туры почмаклы предметлар ясау күнекмәләре бирү<br>-төсле карандашлар белән бизәргә өйрәтү | |
| 25 | Иң матур әйбер ясау | -эстетик кабул итү сәләтен үстерү<br>-матур предметлар ясау теләге булдыру | |
| 26 | Кечкенә китаплар | -өстән-аска, сулдан-уңга хәрәкәт итеп (пумала белән) дуртпочмаклы фигуралар ясарга өйрәтү | |
| 27 | Кубиклар | -квадрат формадагы предметлар ясарга өйрәтү<br>-бер юнәлештә (өстән-аска) сызыктан чыкмыйча буярга өйрәтү | |
| 28 | Сыерчык оясы | -турыпочмаклы формадагы предметлар ясарга өйрәтү<br>-предмет өлешләренең зурлыкларын чагыштырмача дөрес күрсәтергә өйрәтү | |
| 29 | Матур ковер | -төрле харктердагы, туры, вертикаль, авыш сызыклар ясарга өйрәтү-квадрат формасындагы битне бизәкләргә өйрәтү | |
| 30 | Матур арба | -турыпочмаклык, түгәрәк формадагы предметлар ясарга өйрәтү<br>-үз теләге буенча буяу сайлау мөмкинлеге бирү | |
| 31 | Бәйрәм турында | -алган тәэсирләр нәтиҗәсендә матур рәсем ясау теләге булдыру | |
| 32 | Тузганак чәчәге | -рәсемдә чәчәк атучы болынның матурлыгын сурәтләү теләге булдыру<br>-иҗади хезмәт нәтиҗәсендә куану хисләре тәрбияләү | |
| 33 | Уйлау буенча ясау | -тема сайлаганда мөстәкыль эш итәргә өйрәтү<br>-үзең уйлап тапкан бизәкләр куллану мөмкинлеген бирү | |
| 34 | Курчак күлмәге | -шакмаклы бизәк ясарга өйрәтү<br>-буяуларны чиратлаштыру мөмкинлеген бирү | |

**«Иҗади сәнгать» белем бирү өлкәсе.**

**Әвәләү.**

Әвәләү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Балчык, пластилин, тозлы камырның үзенчәлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларны ныгыту.

Балчык, пластилин кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләү; ике кулның уч төпләре белән басып, шарны яссыландыру, уйнар өчен гади генә формалар-коймак, кабартма әвәләргә дәртләндерү.

Әвәләнгән фигуралардан күмәк композиция төзергә тәгъдим итү. Күмәк эшчәнлекнең нәтиҗәсен күреп, шатлану хисләре тудыру.

**Кисеп ябыштыру.**

Балаларны аппликация сәнгатенә тарту, бу эшчәнлек төренә кызыксыну уяту. Орнаментның алдан ук әзерләнгән формаларын кәгазь кисәгендә билгеле бер тәртиптә тезеп куярга уртага, квадрат, түгәрәк кырыйларына урнаштырырга өйрәтү, күмәк композицияләр иҗат итү күнекмәләрен үстерү.

**Иҗади сәнгать.**
**Әвәләү, кисеп ябыштыру буенча тематик планнар.**

| | Тема | Бурычлар | Дата |
|---|---|---|---|
| 1 | Тавышлы пластилин | -пластилинның үзлекләре белән таныштыру (йомшак, әвәләп булла, сытыла)<br>-әвәләп ясарга теләк булдыру | |
| 2 | Юлда шарлар тәгәри | -түгәрәк формадагы предметлар белән таныштыру<br>-ябыштыру алымнарына өйрәтү | |
| 3 | Әвәләү, конфет-лар | -пластилин кисәген өзеп, учларда тәгәрәтеп ясарга өйрәтү<br>-әвәләп ясау теләге булдыру | |
| 4 | Кисеп ябыштыру. Зур һәм кечкенә шарлар | -зурлыклары төрле булган предметларның аерымлыкларын ачыклап, дөрес итеп ябыштырырга өйрәтү. | |
| 5 | Әвәләү. Куянга бүләк | -турыга тәгәрәтеп ясау күнекмәләрен үстерү.<br>-җәнлекләргә дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү. | |
| 6 | Кисеп ябыштыру. Кышка яшелчәләр | -кәгазь битендә иркен ориентлашырга өйрәтү.<br>-хезмәт нәтиҗәсендә сөенү хисләре тәрбияләү. | |
| 7 | Әвәләү. Машина көпчәкләре | -түгәрәкләп ясалган фигураларны кысып, диска әйләндерергә өйрәтү.<br>-транспорт өлешләре турында белемнәрен тирәнәйтү. | |
| 8 | Кисеп ябыштыру. Тәлинкәдә алмалар. | -предмет формасы турындагы белемнәрен ныгыту<br>-клей белән сак эш итәргә өйрәтү<br>-кәгазь битендә иркен ориентлашырга өйрәтү. | |
| 9 | Әвәләү. Крендельләр | -туры хәрәкәтләр ясап уч төбендә тәгәрәтеп ясарга өйрәтү<br>-барлыкка килгән эшләрне чагыштырып, охшаш һәм аермалы якларын ачыкларга ярдәм итү. | |
| 10 | Кисеп ябыштыру. Төрле төймәләр | -төрле төстәге түгәрәкләрне чиратлаштырып ябыштырырга өйрәтү<br>-сенсор тәрбия бирү<br>-ярдәмчеллек, хезмәт сөючәнлек сыйфатларын тәрбияләү | |
| 12 | Әвәләү. Зур һәм кечкенә кабартмалар | -пластилинны тигезсез кисәкләргә бүлеп әвәләп ясарга өйрәтү<br>-фантазияләү мөмкинле<br>ге бирү. | |
| 13 | Кисеп ябыштыру. Пирамидка | -берничә өлештән торган уенчыкны ябыштырырга өйрәтү.<br>-зурлыклары кими бару тәртибендә ябыштырырга өйрәтү. | |
| 14 | Кисеп ябыштыру. Яраткан уенчыгым | -фантазияләрен үстерү<br>-үз хезмәтенең нәтиҗәсенә сөенә белү хисләрен тирәнәйтү. | |
| 15 | Әвәләү Теләгән уенчыгынны ясау. | -әвәләп ясау күнекмәләрен үстерү.<br>-ярдәмләшеп эшләргә булышу. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16 | Кисеп ябыштыру.<br>Кызыл салфетка | -квадрат формасындагы кәгазьгә бизәк ябыштырырга өйрәтү<br>-композицион белемнәрен үстерү.<br>-иҗади, эстетик сәләтләрен арттыру. | |
| 17 | Кисеп ябыштыру.<br>Кар бабай | -түгәрәк формасы һәм зурлык турында белемнәрен арттыру.<br>-өлешләрдән сурәт ясарга өйрәтү | |
| 18 | Әвәләү.<br>Кечкенә курчаклар | -ике өлештән торган предметларны ясар-га өйрәтү; багана-тура һәм түгәрәк-баш.<br>Ике өлешне бер-берсе өстенә кысып ябыштырырга өйрәтү | |
| 19 | Әвәләү.<br>Песи һәм чыпчыклар | -әвәләгәндә хәрәкәтне күрсәтергә өйрәтү<br>-иҗат һәм фантазияләрен үстерү. | |
| 20 | Кисеп ябыштыру.<br>Түгәрәктә бизәк | -түгәрәк кырыена бизәк урнаштырырга ярдәм итү.<br>-зурлыклары буенча чиратлаштырып ябыштырырга өйрәтү. | |
| 21 | Кисеп ябыштыру.<br>Әнигә чәчәкләр | -детальләрдән бизәк ясарга өйрәтү.<br>-эстетик кабул иту, образлы күзаллау булдыру | |
| 22 | Әвәләү.<br>Җимлектә кошлар | -әвәләүдә кош образы тудырырга өйрәтү.<br>Мөстәкыйллек, фантазияләү сәләтен үстеру. | |
| 23 | Әвәләү.<br>Аумас курчак. | -берничә өлештән торучы предмет әвәләп ясарга өйрәтү.<br>-предметны вак детальләр белән бизәү теләге булдыру. | |
| 24 | Кисеп ябыштыру.<br>Флажоклар. | -ике өлештән торучы турыпочмаклы предмет ясарга өйрәтү.<br>-төсләрне дөрес аерырга, атарга өйрәтү. | |
| 25 | Әвәләү.<br>Уенчыклар өчен сый. | -әвәләү темасын үзләре уйлап табуларына ирешү.<br>-уен өчен кирәкле әйберләр ясау теләге булдыру. | |
| 26 | Кисеп ябыштыру.<br>Салфетка | -кәгазь салфеткада түгәрәк квадраттан торган бизәкләр ясарга өйрәтү.<br>-ритм төшечәсен үстерү. | |
| 27 | Әвәләү.<br>Куянкай | -берничә өлештән торучы предмет әвәләп ясарга өйрәтү.<br>-түгәрәк хәрәкәтләр ясап әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. | |
| 28 | Кисеп ябыштыру.<br>Сыерчык оясы | -турыпочмаклык һәм өчпочмактан торган предметлар ясарга өйрәтү.<br>-төсләрне кабул итү сәләтен үстерү. | |
| 29 | Әвәләү.<br>Матур кош. | -берничә өлештән торучы предмет әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү. | |
| 30 | Әвәләү<br>Өч аю тәлинкәсе. | -төрле зурлыктагы савытлар әвәләп ясарга өйрәтү.<br>-түгәрәк хәрәкәтләр ясап әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. | |
| 31 | Кисеп ябыштыру.<br>Тиздән бәйрәм. | -әзер формалардан композиция төзергә өйрәтү<br>-сурәтне матур итеп урнаштырырга булыш | |
| 32 | Әвәләү. Кур-<br>чакларга сый. | -мөстәкыйль эш итәргә өйрәтү<br>-күмәк эштән кәнагатьләнү хисләре алу | |
| 33 | Кисеп ябыштыру. | -берничә предметтан торган композиция төзергә өйрәтү | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Чебиләр болынында | -дөрес, чиста ябыштыру күнекмәләре булдыру | |

**Физик культура» белем биру өлкәсе**

Бурычлар:

- балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау, ныгыту

-культура-гигиена күнекмәләре тәрбияләү

Сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллау булдыру.

Төп хәрәкәтләр:

***Йөрү.*** Төркем белән һәм аерым йөрү; парлап йөрү; түгәрәк буенча йөрү; чәчелеп йөрү; предметлар арасыннан йөрү; предметлар аша атлап чыгып йөрү.

***Йөгерү.*** **Т**уры юнәлештә йөгерү; бер-бер артлы тезелеп йөгерү; акрын темпта йөгерү; шнурлар арасыннан йөгерү.

***Үрмәләү.*** Туры юнәлештә үрмәләү; тактадан үрмәләү; авыш тактадан үрмәләү; гимнастик скамьядан үрмәләү; бау астыннан(30-40 см)үрмәләү.

***Сикерү.*** Ике аякта сикерү; шнур аша сикерү; биеклектән сикерү.

***Ыргыту***. ике куллап туп тәгәрәтү; ике куллап туп ыргыту;(астан, өстән, баш өстеннән, шнур өстеннән), тутырылган капчыклар, шишкалар ыргыту (уң, сул куллар белән)

Гомуми үсеш бирүче күнегүләр:

-кул чуклары һәм җилкә мускуллары өчен күнегүләр.

-арка мускулларын ныгыту, умырткалыкның сыгылмалыгын үстерү.

-корсак мускулларын ныгыту, аяк кулларнын ныклыгын үстерү.

**Физкультура буенча тематик план.**

| № | Бурычлар | Дата |
|---|---|---|
| 1 | -Тәрбияче күрсәтмәсе буенча йөрергә, йөгерергә өйрәтә башлау<br>-тезелеп йөрү күнекмәләрен бирү | |
| 2 | -тәрбияче артыннан тезелеп йөрүне өйрәнүне дәвам итү<br>-туры юнәлештә туп тәгәрәтү күнекмәләре булдыру | |
| 3 | -булмә буйлап чәчелеп йөрергә, йөгерергә өйрәтүне дәвам итү<br>- туры юнәлештә туп тәгәрәтү күнекмәләрен ныгыту<br>-предметлар арасыннан йөрергә өйрәтүне дәвам итү | |
| 4 | -предметлар арасыннан йөрергә өйрәтү<br>-ике аякта сикерергә өйрәтә башлау<br>-үрмәләү күнекмәләрен үстерү | |
| 5 | -ике куллап зур тупны тәгәрәтү күнекмәләре бирү<br>-туп белән уйнарга өйрәтү<br>-чәчелеп йөрү, йөгерү күнекмәләрен бирү | |
| 6 | -тәрбияче сигналы буенча эш итәргә өйрәтү<br>-тупны көч белән этеп җибәрергә өйрәтү | |
| 7 | -1,5 арадан бер-берсенә туп тәгәрәтергә өйрәтү<br>-хәрәкәтле уеннар уйнарга өйрәтү<br>-физик активлыкларын үстерү | |
| 8 | -туры юнәлештә туп тәгәрәтү күнекмәләрен үстерү<br>-хәрәкәтле уеннар уйнаганда физик активлыкларын арттыру | |
| 9 | -бүлмәдә ориентлашырга күнектерү<br>-тәрбияче сигналын тыңлап эш итәргә өйрәтү<br>-шнур астыннан төркемләп үрмәләп чыгарга өйрәтү | |
| 10 | -тигезлек саклап йөрергә өйрәтә башлау | |

| | | |
|---|---|---|
| | -ике аякта предмет тирәли сикереп йөрергә өйрәтү<br>-чәчелеп йөрү, йөгерү күнекмәләрен ныгыту | |
| 11 | -берәрле колоннада йөрергә өйрәтүне дәвам итү<br>-үрмәләү күнекмәләрен үстерү<br>-кыршаудан-кыршауга ике аякта сикереп йөрү | |
| 12 | -бер-бер артлы тезелеп йөрергә өйрәтү<br>-зур тупны ике куллап этеп җибәрергә өйрәтүне дәвам итү<br>-ике аякта сикерү күнекмәләрен үстерү | |
| 13 | - бер-бер артлы тезелеп йөрергә өйрәтүне дәвам итү<br>-урында ике аякта сикерергә өйрәтүне дәвам итү<br>-20 см юлдан йөрергә өйрәтү | |
| 14 | -бер-бер артлы тезелеп йөрергә өйрәтүне дәвам итү<br>-20 см тактадан йөрергә өйрәтү<br>-зур тупны ике куллап этеп җибәрергә өйрәтүне дәвам итү | |
| 15 | -20 см юлдан йөрергә өйрәтүне дәвам итү<br>-ике куллап тупны идәнгә бәрергә һәм тотып алырга өйрәтү | |
| 16 | -берәрле колоннада йөрү күнекмәләрен үстерү<br>-тигезлек саклап йөрергә өйрәтүне дәвам итү | |
| 17 | -40 см юлдан йөрергә өйрәтү<br>-эскәмиядән шуышып чыгып, 3 м арага үрмәләргә өйрәтү | |
